УДК 78

***Ә.К. Әхмәтшина,***
***Р.Җ. Вәлиева***

# ЯР ЧАЛЛЫ ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ СӘНГАТЬ ҺӘМ ДИЗАЙН ФАКУЛЬТЕТЫ: ТАРИХИ ҮСЕШЕ ҺӘМ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

Статья посвящена истории создания и становления факультета искусств и дизайна Набережночелнинского государственного педагогического университета, его роли в подготовке учителей изобразительного искусства и технологии для образовательных учреждений Республики Татарстан. Раскрывается вклад выпускников факультета в развитие изобразительного искусства и художественного образования республики.

**Ключевые слова:** университет, образование, искусство, художник, учитель, дизайнер.

The article is devoted to the history of creation and formation of the faculty of arts and design of Naberezhnye Chelny state pedagogical University, its role in training teachers of fine arts and technology for educational institutions of the Republic of Tatarstan. The article also mentions graduates of the faculty and their contribution to the development of fine arts and art education in the Republic.

**Keywords:** University, education, art, artist, teacher, designer.

2020 елда Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты үзенең 30 еллыгын билгеләп үтте. Югары уку йортында иң өлкән факультетларның берсе – сәнгать һәм дизайн факультеты. Ул үзенең ачылышы белән Алабуга дәүләт педагогика институтының Яр Чаллы филиалы директоры З.Т. Шәрәфетдиновка бурычлы. 1984 елда Алабуга дәүләт педагогика институты ректоры, филология фәннәре докторы, профессор Т. Н. Галиуллин боерыгы белән художество-графика факультеты ачыла һәм I курска студентлар алу турында игълан ителә. Факультет ачылу халык мәгарифенең «Татарстан Республикасы өчен педагогларга – рәссамнарга (тасвирый сәнгать, сызым һәм хезмәт укытучыларына) ихтыяҗ кичерүе» белән бәйле була [Шарафутдинов, с. 40]. Художество-графика факультетында укырга теләгән абитуриентларның күп булуы иҗади белгечлекне ачуның дөрес һәм бик тә вакытлы булуын дәлилләде. Художество-графика факультеты Татарстан, күрше төбәкләр мәктәпләрен тәмамлаучылар арасында гына түгел, ә урта һөнәри уку йортлары – Чаллы сәнгать көллияте, Лениногорск сәнгать-педагогика көллиятенең кичәге укучылары арасында да популярлык казанды. Факультетның укытучылар составы алдында гомуми белем мәктәпләре һәм сәнгати белем учреждениеләренә рәсем, сызым һәм хезмәт укытучылары әзерләү өчен шартлар тудыру бурычы куелды.

Факультетта укыту эшенә профессиональ рәссамнар, сәнгать белгечләре – Н.А. Розенберг, С. Шишкина, Д. Прокудин, А. Мельников,

Н. Шелкова, К. Сафиуллин, Б. Степанов, М. Зуева, А. Низаметдинова, В. Коростылев, Т. Шагова, Л. Семенова, А. Фәйзуллин һәм башкалар җәлеп ителә. Аларның күбесе Яр Чаллы шәһәренә Мәскәү, Ленинград, Казан, Чабаксар, Магнитогорск югары сәнгать уку йортларын тәмамлаганнан соң килгән. Төрле елларда факультетта А. Әхмәдова, Г.М. Нигъмәтҗанова, Р. Шәрәфетдинова, Т. Васильева, Ф. Сөләйманова, Л. Гатиятуллин, А. Гатиятуллина, Г. Клименко, Е. Чибирева, Р.М. Минсабиров, Р.Н. Сәлахетдинов һ. б. укыта. Художество-графика факультетында иҗатлары шәһәр һәм республикадан читтә дә билгеле Ю.Свинин, В. Акимов, А. Петров, Х. Шәрипов, А. Халдеев, Б. Гыйльванов, Р. Латыйпова-Иванова кебек рәссамнар да эшли.

Уку-укыту процессын һәм факультетның матди-техник базасын оештыруга Түбән Тагил, Магнитогорск, Чабаксар педагогия институтлары белгечләре дә тартыла. Аларның кайберләре озак эшләми, ә икенчеләре дистәләрчә еллар дәвамында үз эшчәнлекләрен художество-графика факультеты белән бәйли.

В.А. Клименко, педагогика фәннәре кандидаты, Магнитогорск шәһәреннән килгән доцент, Магнитогорск дәүләт педагогия институтының художество-графика факультетында укыткан, Егерме елдан артык Яр Чаллы дәүләт педагогика институтының художество-графика факультетында эшләгән. Ул – сынлы сәнгать кафедрасын оештырган һәм аның беренче мөдире дә булган шәхес. В.А. Клименко чыгарылыш сыйныф укучылары күңеленә «сызым» предметы белән мавыккан укытучы буларак кереп калган, ул мизгел эчендә тактаны сызып тутырып, студентлары белән бергә формулалар һәм мәсьәләләр дөньясына «чума» алган. Күпмедер вакыт мәктәпләрнең уку-укыту планнарына сызым фәне бөтенләй кертелмәде, ә хәзер исә вузларда техник юнәлешләр буенча белем алучыларның саны арту сәбәпле, Татарстанның күп кенә мәктәпләрендә сызым кабат укытыла башлады. Укытучылар арасында художество-графика факультетын тәмамлаучылар да шактый. Кафедра мөдире булып төрле елларда А.У. Яппаров, К.Х. Кәрамова, В.Н. Минсабирова эшли.

Яр Чаллы дәүләт педагогика институтының художество-графика факультетында укытырга педагогик вузларны да тәмамлап киләләр. А. И. Яншин 1984 елда «сызым һәм сынлы сәнгать» белгечлеге буенча Чуваш дәүләт педагогия институтын тәмамлый, ә инде 1985 елда Яр Чаллы дәүләт педагогика институтының художество-графика факультетында мөгаллимлек итә башлый. А.И. Яншин бер үк вакытта фәнни һәм укыту эшчәнлеге белән дә шөгыльләнә, кандидатлык диссертациясе яклый һәм доцент була. 1987 елда рәсем, нәкыш, композиция һәм декоратив-гамәли сәнгать дәресләре үткәрү өчен (белгечлек – Россия халык промыселларында пумала белән диварга декоратив бизәк төшерү), В.И. Ленин исемендәге Ленин орденлы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Мәскәү дәүләт педагогика институтының художество-графика факультетын тәмамлаган В.С. Бадаев сынлы сәнгать

кафедрасы ассистенты итеп кабул ителә. 1994 елда – кандидатлык, ә аннары докторлык диссертациясен яклый.

Берничә ел дәвамында факультетта, укытучыларның актив катнашлыгы белән, нәкыш, рәсем, скульптура, гипсны уеп-кисеп бизәк төшерү, агач һәм металлны, тукымаларны һәм башка материалларны эшкәртү буенча техник яктан җиһазландырылган остаханәләр булдырыла. Уку чорында студентлар һөнәрчелек төрләре, материаллар эшкәртүнең борынгы һәм заманча технологияләре белән танышалар. Факультетта офорт остаханәсе дә җиһазландырыла, аңа ТР һәм РФ Рәссамнар берлеге әгъзасы А. Халдеев җитәкчелек итә. Офорт остасы үз студентларын эстамп сәнгате белән кызыксындыра, хәтта кайбер шәкертләре киләчәктә аның эшен дәвам иттерә. Бүгенге көндә художество-графика факультетын тәмамлаган яшь рәссамнар – Марат Мингалиев, Игорь Евграфов, Рушания Шәйхетдинова, Айгөл Мөнирова – Александр Халдеев исемендәге графика остаханәсен булдырып, басма графика сәнгатен популярлаштыралар. Факультетта укыган вакытта студентлар фәннәрне, педагогиканы, психологияне укыту методикасы буенча белем генә түгел, ә сынлы сәнгатьнең төрле төрләре буенча югары дәрәҗәле әзерлек алалар. Бу аларның иҗади һәм сәнгати потенциалын гамәлгә ашырырга мөмкинлекләр ача.

Факультетта уку-укыту озак вакытлар «специалитет» программасы нигезендә алып барылды, ул уку йөкләнешенең шактый өлешен (якынча 4000 сәгать) – махсус әзерлек фәннәре буенча аудитор дәресләргә бирүне күздә тотты һәм югары квалификацияле педагог-рәссамнар әзерләп чыгаруны тәэмин итә алды. Чыгарылыш курс студентларының университет бинасы эченә урнаштырылган иҗади эшләре буенча гына да аларның нинди югары һөнәри әзерлеккә ирешүләре турында фикер йөртеп була.

Күп кенә чыгарылыш курс студентлары педагогик эшчәнлек белән дә шөгыльләнәләр, иҗаттан да читләшмиләр, күргәзмәләрдә, сәнгать тормышының төрле вакыйгаларында актив катнашалар. 1991 елда татар бүлегенә дә студентлар кабул ителә, факультет, нигездә, авыллардан татар мәктәпләрен тәмамлап килүчеләргә сәнгати белем алырга мөмкинлек бирә, «туган телдә укырга теләүче абитуриентларга юл ача» [Шарафутдинов, с. 40]. Авыл җирләреннән килгән чыгарылыш сыйныф укучылары өчен художество-графика факультетына укырга керүнең авырлыгы – аларның сәнгати әзерлеге булмауда. Чөнки авыл баласының сәнгать мәктәбендә, студияләрдә уку мөмкинлеге юк. Факультетта абитуриентларны махсус фәннәр буенча укырга керү имтиханнарына әзерләү курслары эшли. Нәтиҗәдә алар кыенлыкларны җиңеп чыгалар һәм керү имтиханнарын уңышлы тапшыралар. Татар бүлеге студентлары хезмәт сөючәнлекләре, укырга, белергә омтылулары белән аерылып торалар, шуңа күрә алар махсус әзерлек фәннәрендә белемнәрен, осталыкларын һәм күнекмәләрен бик тиз тулыландыралар. Татар бүлеген оештыруда һәм аның эшчәнлеген гамәлгә ашыруда архитектура кандидаты, доцент А.У. Яппаров-

ның өлеше гаять зур. 1993 елда татар һәм рус бүлекләрендә читтән торып уку формасы да оештырыла.

1990 елда художество-графика факультетының беренче чыгарылышы студентлары «сынлы сәнгать, хезмәт һәм сызым укытучысы» квалификациясе белән югары белем турында дипломнар алалар. Алар арасыннан иң сәләтлеләре һәм талантлылары факультетның профессор-укытучылар составын тулыландыралар. Шушы факультетны тәмамлаучылардан И.В. Комадорова, В.Н. Минсабирова, Л.Р. Букина, А.Х. Шәйхелисламов, К.Х. Кәрамова, Э.Г. Әхмәтшина, И.В. Лебедева, А.Р. Гатина, С.М. Арефьева, Н.В., Т.В. Васильева, Л.Л. Хәмитова, Т. Азиуллина, Д.А. Хәмзина, Г.А. Лотфуллина, Ч.Д. Йосыпова, М. Сәлахетдинов, Н.В. Әмирова, Ф.Ф. Гайфетдинов, Л.Х. Кадыйрова, Р.Җ. Вәлиева, С.В. Большакова, Б.В. Киселев, Л.А. Батаева, Г.В. Әхтәмова һ.б. биредә укыттылар һәм бүген дә укыталар.

ХГФны тәмамлаучылар, укытучылар Н.В. Әмирова, Л.А. Батаева Яр Чаллы педагогика институты аспирантурасында укуларын дәвам итәләр, 13.00.02 – белем бирү һәм тәрбия теориясе һәм методикасы (сынлы сәнгать) белгечлеге буенча сынлы сәнгать кафедрасы профессоры В.С. Бадаев җитәкчелегендә кандидатлык диссертацияләрен яклыйлар.

Үз тарихында факультет республика шәһәрләре һәм районнары өчен бик күп белгечләр әзерләде. Татарстан Республикасының шәһәр һәм төбәкләре балалар сәнгать мәктәпләрендә штаттагы педагогларның күбесен сәнгать факультетын тәмамлаучылар тәшкил итә. Алар арасында: 1 фәннәр докторы, 15 фән кандидаты, 20 кеше – Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, 11 кеше – Россия Дизайнерлар берлеге һәм Россия Архитекторлар берлеге әгъзалары. Безнең институтны тәмамлаучылар шәһәрдә һәм төбәктә югары һәм профильле сәнгатиэстетик белем бирү өлкәсендә күп кенә уку йортларына җитәкчелек итәләр, иҗтимагый оешмаларның башында торалар. Э.Г. Әхмәтшина – педагогика фәннәре кандидаты, доцент – «Кама сәнгать һәм дизайн институты» Хосусый Югары белем бирү учреждениесе ректоры, С.Р. Сапожникова – «Алабуга муниципаль районының И.И. Шишкин исемендәге 1 нче номерлы Балалар сәнгать мәктәбе» Муниципаль бюджет балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе җитәкчесе. Г.Т. Шәрәфетдинова Яр Чаллы шәһәренең «2 нче номерлы Балалар сәнгать мәктәбе» Муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесендә бүлек мөдире булып эшли һәм Халыкара педагог-рәссамнар берлегенең Татарстан Республикасындагы вәкиллегенә җитәкчелек итә. И.Н. Максимов – атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллиятенең дизайн бүлеге мөдире.

Ф.Ф. Гайфетдинов – ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Россия Рәссамнар берлеге»нең Яр Чаллы бүлегенә җитәкчелек итә. М.И. Мингалиев «Яр Чаллы картиналар галереясы» МБУнең фәнни эш буенча директор урынбасары, «Эстамп кабинеты» иҗади остаханәсен җитәкли. Факультетның элеккеге студентлары мәгариф һәм мәдәният өл-

кәсендә югары профессиональ категорияләр, исем һәм дәрәҗәләргә лаек булды. И.И. Шишкин исемендәге 1 нче номерлы Балалар сәнгать мәктәбенең югары категорияле укытучысы Г.В. Власова Татарстан Республикасының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнде. Г.А. Колчерина, «Энергетик» мәдәният сараеның баш бизәүче рәссамы – Яр Чаллы шәһәре мэры премиясе лауреаты.

Сер түгел: теләсә кайсы структур подразделениенең уңышлы эшчәнлеге турыдан-туры җитәкче, бу очракта декан хезмәте белән бәйләнгән. Уку процессын оештырудагы барлык яңалыклар художество-графика факультеты деканнары ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Факультет белән төрле елларда Ю. Окунев, Р.Н. Ярмиев, Р.М. Зәйниев, А.В. Халдеев җитәкчелек итә. В.С. Бадаев 1995 елда декан итеп сайлана һәм әлеге вазифаны 2014 елга кадәр били. Ул укытучылардан һәм студентлардан бердәм фикердәшләр коллективы формалаштыра, факультетта иҗади атмосфера тудыра, даими рәвештә Яр Чаллы педагогика институты җитәкчелеге белән факультет студентларының Санкт-Петербург, Мәскәү һәм Европа шәһәрләренә музей һәм пленэр практикаларына баруларын финанслау мәсьәләсен хәл итә. Музей экспозицияләренә бару, аларны өйрәнү буенча авторлык программалары сәнгать тарихы укытучылары С.М. Арефьева һәм Т.В. Васильева тарафыннан эшләнә.

2008 елда Гыйльми совет карары буенча художество-графика факультетында дизайн өлкәсендә белгечләр әзерләү өчен дизайн кафедрасы оештырыла. Уку процессын оештыруга безнең шәһәр дизайнерларының инициатив төркеме, шул исәптән ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Дизайнерлар берлеге әгъзасы, мәдәният өлкәсендә РФ Дәүләт премиясе лауреаты В.И. Хайман да зур өлеш кертә. Ул 2008–2015 елларда дизайн кафедрасы мөдире булып эшли. 2010 елдан факультетның «Дизайн» юнәлешендә укучы студентлары урта һөнәри белем программасы буенча шөгыльләнәләр.

Педагогик фәннәр кандидаты, доцент С.Р. Смирнова (Гыйльметдинова) 2003 елдан сынлы сәнгать кафедрасына мөдирлек итә, ә 2014–2018 елларда декан вазифасын башкара. Факультет белән җитәкчелек иткән елларда С.Р. Смирнова «Социаль-мәдәни эшчәнлек» профиле буенча бакалаврлар әзерләүдә яңа юнәлеш ачу өчен документлар әзерли. 2017 елда «Социаль-мәдәни эшчәнлектә менеджмент» профиле буенча 1 курска студентлар кабул ителә.

2014 елда факультет «Сәнгать һәм дизайн факультеты» дип үзгәртелә. 2018 елда декан вазифасына архитектура кандидаты Е.С. Пономарев сайлана. 2019 елдан факультетның деканы – педагогика фәннәре кандидаты, доцент Р.З. Вәлиева.

Хәзерге вакытта факультетта «Сынлы сәнгать һәм технология», «Дизайн» (әйләнә-тирә мохиттә), «Социаль-мәдәни эшчәнлек менеджменты» профильләре буенча белгечләр әзерләнә. 2018 елдан «Педагогик белем» юнәлешенең «Сәнгати белем» профиле буенча укыту магистратура программасы буенча алып барыла. Ачылган елдагы

кебек үк (факультет 35 ел эшли) мәктәпләрнең һәм урта һөнәри уку йортларының чыгарылыш сыйныф укучылары арасында факультет бик популяр, анда укырга кереп белем алуга сорау зур. Юнәлешләрнең популярлыгы хезмәт базарында «сынлы сәнгать һәм технология укытучысы», «дизайнер» квалификациясе алган белгечләргә ихтыяҗның үсүе белән бәйле. Факультетны тәмамлаучылар урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә, сәнгати-эстетик юнәлешле студияләрдә рәсем һәм технология укытучылары булып эшлиләр. Факультетны тәмамлаучылар шәһәрнең сәнгати мохитен формалаштыруда актив катнашалар, еш кына мәдәни һәм белем бирү башлангычларының инициаторлары булып торалар. Менә күп еллар инде балалар һәм ата-аналар арасында факультетны 1991 елда тәмамлаган А.А. Шустов һәм С.В. Большакова тарафыннан оештырылган «АРТ-ГРАФИК» студиясе бик популяр.

Сәнгать һәм дизайн факультеты (художество-графика факультеты) беренче көннәреннән үк үзендәге иҗади атмосфера белән аерылып тора. Укытучылар һәм студентлар Яр Чаллының, шулай ук Татарстан һәм Россия шәһәрләренең мәдәни мәйданчыкларында узган күргәзмәләрдә катнашалар, тамашачыларга графика, нәкыш, декоративгамәли сәнгать, шулай ук әйләнә-тирә мохит дизайны буенча эшләнгән иҗади һәм проект эшләрен тәкъдим итәләр. Студентлар ел саен үткәрелә торган «Ел рәссамы» шәһәр конкурсында, «Яр Чаллы картиналар галереясе» МУПның график арт-проектларында катнашалар. Кафедра укытучылары студентның иҗади потенциалын, аның билгеле бер иҗади эшчәнлек төренә сәләтен күреп, дөрес бәялиләр, аңа сәнгатьтә үзен табарга ярдәм итәләр һәм алга таба үсеш перспективаларын күрсәтеп, осталык һәм күнекмәләрен гамәлгә ашырырга булышалар. Хәзерге вакытта факультетта күргәзмә эшчәнлегенә РФ Рәссамнар берлеге әгъзасы, педагогика фәннәре кандидаты, доцент С.В. Большакова; доцент, РФ Дизайнерлар берлеге әгъзасы Г.А. Гыйзетдинова; педагогика фәннәре кандидаты, доцент Р.З. Вәлиева кураторлык итә.

Ел саен Россиянең беренче Президенты Б.Н. Ельцин исемендәге Урал федераль дәүләт университеты үткәрә торган «Мәдәният һәм экология – Россиянең тотрыклы үсеше нигезләре» Халыкара форумы, укучы яшьләр һәм мәктәп укучылары өчен В.Е. Татлин исемендәге Бөтенроссия архитектура-сәнгать иҗаты конкурс-олимпиадасы жюрие тарафыннан студентларының эшләре югары бәяләнә, аларга беренче урыннар бирелә. Студентларның «Архитектура һәм сәнгать территориясе» тематик мәйданчыгындагы иҗади проектлары «Безнең Татарстан» Республика форумын оештыручыларның һәм анда катнашучыларның хәтеренә тирән уелып калды. Факультет студентлары 2020 елның 13–25 сентябрендә Алабуга шәһәрендә уздырылган «BASHNYA» III Халыкара яшь рәссамнар лабораториясе эшендә катнаштылар.

Сәнгать һәм дизайн факультеты студентлары фәнни-тикшеренү эшләре белән дә шөгыльләнәләр. Ел саен факультет студентлары МДУ тарафыннан үткәрелә торган «Ломоносов» конференциясендә

катнашалар. Доцент, сәнгать фәннәре кандидаты Ә.К. Әхмәтшина җитәкчелегендә еш кына беренче урыннарны алалар.

Декоратив-гамәли сәнгатьнең төрле төрләре буенча факультет студентлары үткәрә торган мастер-класслар да (доцентлар А.Р. Вәҗиева, Р.Җ. Вәлиева һәм С.В. Большакова җитәкчелегендә) Татарстан шәһәрләре һәм районнарында яшәүчеләрнең хәтерендә калды. Мастер-класслар «Минем һөнәри векторым» һәм «ИНТЕЛ.КВЕСТ» дип аталган югары уку йортлары проектлары кысаларында балалар һәм яшүсмерләр өчен ял итү-белем бирү мәйданчыгы буларак үткәрелә.

Булачак дизайнерлар Яр Чаллы дәүләт педагогика институты һәм шәһәр күләмендә үткәрелә торган чараларны, шәһәр тирәлеген һәм шәһәрнең җәмәгать биналарын бизәү буенча проектларга җәлеп ителә. Факультет студентлары тарафыннан шәһәрнең берничә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, спорт-сәламәтләндерү комплексы бизәлде. Проектларның кураторлары – кафедра укытучылары Е.А. Сафиуллина, Н.П. Петрушин, архитектура кандидаты Е.С. Пономарев, А.С. Кузнецова (барысы да РФ Дизайнерлар берлеге әгъзалары).

Төрле елларда сәнгать һәм дизайн факультеты студентлары тарафыннан башкарылган иҗади эшләр университет биналарының интерьерына куелган.

Хәзерге вакытта факультетта 200 гә якын студент белем ала (шул исәптән «Дизайн» урта һөнәри белем бирү программасы буенча (сәнәгать өлкәсендә). «Педагогик белем» юнәлешендә урта һөнәри белем бирү программасы буенча «Сынлы сәнгать һәм сызым», шулай ук яңа стандартлар нигезендә яңартылган югары белем бирү программалары буенча «Сынлы сәнгать һәм дизайн», «Технология» өстәмә профильләрен ачу планлаштырыла.

Факультет укытучылары һәм студентлары тарафыннан мәктәп һәм колледж укучылары арасында актив профориентация эше алып барыла. Факультетка абитуриентларны җәлеп итү максаты белән ел саен үткәрелә торган олимпиадалар, сынлы сәнгать һәм технология буенча конкурслар традициягә әйләнде. Сынлы сәнгать буенча олимпиада урта гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына рәсем, нәкыш һәм композицияләр буенча иҗади потенциалларын бәяләргә мөмкинлек бирә. «Заманча матди, информацион һәм социаль технологияләр» конкурсы технология өлкәсе белән кызыксынучы укучыларны бергә җыя һәм үзләренең иҗади проектларын тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә.

Факультетның матди-техник базасы елдан-елга нәкыш, рәсем, төрле материалларны, тегелгән әйберләрне, металл, агач, пластик материалларны, азык-төлек продуктларын эшкәртү остаханәләре өчен яңа техник җиһазлар белән тулыландырыла, бу исә гамәли күнекмәләр алырга һәм дисциплиналар буенча уку-укыту материалын тулырак үзләштерергә мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта, уку остаханәләре техник яктан яхшы итеп җиһазландырылу нәтиҗәсендә,

иҗади проектларны һәм чыгарылыш квалификация эшләрен югары профессиональ дәрәҗәдә гамәлгә ашырып була (лазер белән кисү, санлы программа идарәсе булган граверлау-фрезерлы станок, муфель миче һәм башка җайланмалар ярдәмендә төрле материаллардан оригиналь сувенирлар, декор яки йорт җиһазы предметлары әзерләү). Киләчәктә керамика һәм пыяла, шулай ук агач һәм металл буенча мөстәкыйль эш төрләренә караган уку остаханәләренең санын арттыру планлаштырыла.

Факультетның үсешендә гомуми, өстәмә һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек зур роль уйный. Ә шәһәрнең алдынгы архитектура-төзелеш һәм дизайнер предприятиеләре белән хезмәттәшлек итү студентларга, проектлаштыруның яңа технологияләрен кулланып, дизайн-проектлау эшчәнлегендә күнекмәләр алырга мөмкинлек бирәчәк.

Яңа дәүләт стандартында махсус әзерлек дисциплиналары буенча аудитор эшнең гомуми күләме киметелгән, шуңа күрә «белем бирү процессын интенсивлаштыруның яңа юлларын һәм чараларын эзләү, аның нәтиҗәлелеген күтәрү проблемасы беренче планга чыга» [Бредихин, с. 56]. Уңышлы уку-укыту процессына, күп яктан, факультет укытучылары тарафыннан тудырылган уңайлы белем бирү мохите дә ярдәм итә. Сәнгать һәм дизайн факультетына укырга кергән абитуриентлар укытучылар һәм укучылар арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр хөкем сөргән мохиткә килеп эләгә, һәм мондый мөнәсәбәтләр үзара хөрмәт, ярдәмләшү, хезмәттәшлек итүгә нигезләнә. Бары тик шундый шартларда гына универсаль, гомумпрофессиональ компетенцияләр формалаша, һәр студентның шәхес буларак үсеше өчен мөмкинлекләр тудырыла.

### Әдәбият

*Бредихин А.П.* Проблемы современного художественно-педагогического образования в контексте «Модернизации: Время траченных иллюзий». Воронеж: Известия ВГПУ. № 1 (262). 2014. С. 56.

*Султанова Р.Р.* Искусство новых городов Республики Татарстан (1960–1990). Живопись, графика, монументально-декоративное искусство, скульптура. Казань, 2001. 194 с.

*Шарафутдинов З.Т.* Становление и развитие Набережночелнинского педагогического института. Информационно-справочное издание. Набережные Челны: Газетно-книжное издательство «КамАЗ», 1997.

***Әхмәтшина Әнифә Камай кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университетының сәнгать һәм инновацион дизайн кафедрасы доценты*

***Вәлиева Регина Җәүдәт кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, Яр Чаллы дәүләт педагогика университетының сәнгать һәм инновацион дизайн кафедрасы доценты, сәнгать һәм дизайн факультеты деканы*